ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балигъ булган яшьтәге ир-ат йә хатын-кыз уллыкка алучылар булырга мөмкин, моңа түбәндәгеләр керми:

1) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

2) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган ир йә хатын;

3) суд тарафыннан ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары чикләнгән затлар;

4) закон белән йөкләнгән үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;

5) элек уллыкка алганнар, әгәр уллыкка алу алар гаебе аркасында суд тарафыннан юкка чыгарылган булса;

6) сәламәтлек торышы буенча баланы уллыкка ала алмый торган затлар. Затның баланы уллыкка алу, аны опекага яисә попечительлеккә алу, бала алучы гаиләгә яисә патронат гаиләгә алу мөмкинлеген юкка чыгара торган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка алырга теләгән затларны медицина таныклавы гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уздырыла;

7) уллыкка алуны билгеләү вакытына уллыкка алынучы баланы тәэмин итәрлек, Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләмендәге кереме булмаган затлар;

8) даими яшәү урыны булмаган затлар;

9) әлеге өлешнең 10 пунктында каралган очраклардан тыш, шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы җинаятьләр өчен, шулай ук шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хәзерге вакытта яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә хәзерге вакытта яисә элегрәк дучар булган затлар (җинаять эзәрлекләве реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылган затлардан тыш);

10) әлеге өлешнең 9 пунктында күрсәтелгән затлар арасыннан булган, шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы авыр яисә аеруча авыр җинаятьләргә караган җинаятьләр өчен хөкем ителгән йә җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар, мондый затлар суд тарафыннан уллыкка алына торган баланың гомеренә, сәламәтлегенә һәм намусына куркынычлы дип танылган очракта. Суд, баланың уллыкка мондый зат тарафыннан алынуы турында карар кабул иткәндә, уллыкка алына торган баланың тулы физик, психик, рухи һәм әхлакый үсешен баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янамыйча тәэмин итү мөмкинлеген билгеләү максатларында, затны җинаять эзәрлекләвенә дучар иткән гамәлнең шартларын, гамәл кылган вакыттан соң узган срокны, гаеп рәвешен, шәхесне характерлый торган шартларны, шул исәптән мондый затның гамәл кылганнан соңгы үз-үзен тотышын һәм башка шартларны исәпкә ала;

11) әлеге өлешнең 9 пунктында күрсәтелгән җинаятьләргә карамаган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән затлар;

12) әлеге статьяның 6 – 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы яисә элек уллыкка алган булган һәм үзләренә карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан һәм балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларын үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш);

13) бер үк җенестәге затлар арасында төзелгән берлектә торучы затлар, ул мондый өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә өйләнешү дип танылган һәм теркәлгән булса, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булып торучы һәм өйләнешмәгән затлар.»;

2) 2 һәм 3 өлешләрдә «11» санын «12» санына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 43-ТРЗ